Бүгенге санда



Хөкүмәт ярдәмен рейтинг билгели. 4 бит

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 27 ноябрь 2015 ел

№87 (10616)

**28 ноябрьгә һава торышы:** болытлы һава, җил көнбатыштан, 4-5 м/с; температура көндез -5°С, төнлә -4°С

КОТЛАУ

**Кадерле хатын-кызлар! Сөекле әниләр!**

Искиткеч, үзгә бер мәхәббәт һәм наз белән тулы эчкерсез һәм якты бәйрәм – Әниләр көне белән ихлас котлауларымны кабул итеп алыгыз! Бу бәйрәм барыбыз өчен дә мөһим. Ул сез, кадерле әниләребезгә, кызларыгыз һәм улларыгыздан тирән хөрмәт һәм мәхәббәт, сезнең җәмгыятьтәге зур ролегезне тану билгесе. Районыбыздагы әниләрнең югары багланышы һәм социаль җаваплылыгы турында саннар да сөйли: 407 бала яңа гаиләләрдә ата-ана җылысы, мәхәббәт һәм кайгырту тапты, бездә 562 гаилә җир участоклары алды. Ана капиталы программасы гамәлгә кергән 2007 елдан бирле 3216 әни сертификатлы булды.

Кадерле әниләребез, батырлыгыгыз, хезмәтегез, чиксез мәхәббәтегез һәм фидакарьлегегез, зирәклегегез һәм сабырлыгыгыз өчен алдыгызда баш иябез!

Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, гаиләләрегезгә җылылык һәм күңелләрегезгә тынычлык телим. Балаларыгыз сезне һәрчак сөендереп торсын!

**Равил Кузюров,**
**Нурлат муниципаль районы һәм шәһәре башлыгы**

## ЯҢА УРАМНАР ГАЗ АЛА

Чәршәмбе көнне Нурлаттагы яңа Көньяк-Көнчыгыш микрорайонындагы Ипподром һәм Миләшле урамнарына һәм Югары Нурлат микрорайонындагы Яңа урамга газ бирелде. Бу эшне “Стройгаз” оешмасы башкарган. Шәһәр башкарма комитетында әйтүләренчә, киләсе елдан күпбалалы гаиләләр өчен Аэропорт һәм Кормыш микрорайоны тирәсендә бирелгән участокларга челтәр газы сузу өчен проектлар ясарга керешәчәкләр.

## БАШКАЛАДА ҖИДЕНЧЕ ЯРМИНКӘ

Бу шимбәдә районның авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре Казанда авыл хуҗалыгы ярминкәсендә катнашып, Агросәнәгать паркында башкала халкына киң ассортиментта продукция тәкъдим итәчәкләр. Бу нурлатлыларның Казан ярминкәләрендә җиденче тапкыр катнашуы инде, декабрь азагына кадәр исә тагы ике тапкыр барачаклар.

29 НОЯБРЬ – ӘНИЛӘР КӨНЕ

# Өч кызы бар – өч шатлыгы



Автор фотосы

Яшь әни Рузилә Гыйматова гаилә бәхетен балаларда күрә

**Нурлатлы яшь гаилә Рузилә һәм Марсель Гыйматовлар һәр баланың үз бәхете белән тууына үз мисалларында инанган.**

Бүген өч кызларына шөкерана итеп, яңа көнгә планнар корып яши күпбалалы гаилә. Балаларны аякка бастырып, белемле итү, йорт салу ниятләре дә бар. Үзләренә күп балалылар өчен җир участогы да биргәннәр.

- Хыяллар тормышка аша, - ди Рузилә кызлары Камилә, Мәдинә һәм Ясминәгә сөенеп. – Иң мөһиме – балаларыбыз сау – сәламәт. Әни булуның бөтен тәмен төпчегем Ясминә тугач аңладым. Төпчегебезне 9 ай буена малай булыр дип уйлап йөргән идек, югыйсә. Ә бүген өч кызымның бер – берсенә иптәш, дус, сердәш һәм якын булып үсүләренә шатланып туя алмыйм.

Гыйматовларның зур кызлары Камиләгә 9 яшь кенә булса да, ул – әти-әнисенең беренче ярдәмчесе. “Күпбалалы гаиләдәге балалар башкалардан кай ягы белән аерылып тора?” - дигән сорауга да Рузилә озак уйламыйча:

- Тырышлыклары белән. Нәниләрне үстерүдә ирем һәм әти – әниләрем, туганнарым белән беррәттән зур кызым да булыша. Кызым бөтен эшне белә. 6 яшьлек Мәдинә дә апасыннан калмаска тырыша. 2 яшьлек Ясминә дә апаларына охшамакчы. Рәсемнәр ясый, пластилиннан әвәләү белән мавыга. Өч бала, өчесенең дә үз холкы, – дип җавап бирде.

Мәктәп-бакчадан кайткач, балалар компьютер артына утырырга ашыкмый. Кулларында айпад, айфоннар да юк. Әти - әниләренең үз көчләренә генә таянуын белеп үсәләр. Гыйматовлар гаиләсендә матди байлыкны түгел, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләүне өстен күрәләр.

Күпбалалы гаиләдә чыгымнар турында да сөйләргә яратмыйлар.

- Кулдан килгәннең барысын да үзебез башкарабыз, - диләр елмаеп. – Вакыт булганда, бергәләшеп тимераякка да басабыз, спорт белән шөгыльләнәбез. Спорт дигәннән, район күләмендә узучы чараларны да күз угыннан ычкындырмый Гыйматовлар. Әнә, DFM-Нурлат радиосы үткәргән гаилә бәйрәмендә катнашып II урынны да яулаганнар. Буш вакытларында кызлар әниләре янында кухняда әвәрә килә, бер – берләренә прическалар ясарга да вакыт табалар.

Күпбалалы гаилә бүгенге тормышларыннан канәгать.

- Безгә насыйбы барыбер безгә килә, - диләр Рузилә белән Марсель. – Иң мөһиме – шөкерана итә белергә кирәк. Менә шул вакытта бәхет елмая ул.

Зилия ӘКСАНОВА

АКТУАЛЬ

# Кышкы балык тотуның үз кагыйдәләре

**Елгаларга яткан боз катламы әле юка гына, әмма балыкчылар инде елга ярына җыелырга да өлгергән.**

Ә бит кышкы балык тоту чоры әле башланмады да үзе, ә балыкчылар белән бәйле гадәттән тыш хәлләр бар инде. 20 ноябрь көнне Казанка елгасында ярдан 5 метр ераклыктан коткаручылар ике ир-ат мәетен чыгаралар. Баксаң, иртән алар балыкка дип киткәннәр, ә кичен, кайтмагач, туганнары эзли башлап, яр буенда башлыклары һәм бияләйләренә, ярылган бозга тап булалар.

- Кышын балык тотарга яратучылар безнең районда да бар, - ди районның баш аучысы Ринат Мостафин. – Башлыча алар Чирмешән, Кондырча, Сөлчәгә йөриләр, Камага баручылар да бар. Әмма боз юка әле, һәм балык тоту куркыныч.

Бозга 8-10 сантиметр булып туңу белән чыгарга ярый дип саналса да, аучы ашыкмаска киңәш итә.

– Бозның 12 сантиметрга җитүе яхшы, чөнки ул бар җирдә дә тигез булып туңмый бит. Агым көчле урыннарда юкарак була, - ди Ринат Мостафин.

Кышкы балыкчылык суык көндә бәке янында утырырга яратучыларны гына түгел, браконьерларны да үзенә җәлеп итә. Аучы әйтүенчә, безнең районда андый кешеләр бар һәм законсыз балык тотуга җәен генә түгел, кыш көне дә чыгалар. Мәсәлән, җәйге чорда ятьмәләрне законсыз урнаштырган өчен аучы 4 административ беркетмә төзегән. Рейдлар хәзер дә үткәрелә. Һәм җиңел табыш турында фикер ничек кенә матур тоелмасын, браконьер булганчы, һәвәскәр балыкчы булып калуың хәерлерәк. Сулыкларда бозның ныклап катуын көтәргә кирәклеген дә аңлаган хәлдә, әлбәттә.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

Дуслык Дружба Туслăх

**Игътибар!**

**3–13 декабрь – Әбунәункөнлеге**

*Сез бу чорда “Дуслык”ка ташламалы бәя – 487 сум 86 тиеннән язылa аласыз.*

*Ашыгыгыз! Сезне почта бүлекчәләрендә һәм редакциянең реклама бүлегендә көтәбез!*

“ДОКТОР “ДУСЛЫК”

# Сезнең йортка ләкләк килде




**Сәламәт бала табу һәм үстерүдә мәгълүмати ярдәм күрсәтүне максат иткән “Доктор “Дуслык” проектының чираттагы тукталышы – бала тудыру йорты. Әлеге мөһим моментка ничек әзерләнергә һәм ничек катлауланусыз узарга – бүген шул хакта сөйләшәбез. Без бу этапны район үзәк хастаханәсенең акушерлык – физиология бүлеге мөдире Ольга Волкова белән бергә узачакбыз.**

**Безнең белешмә: Ольга Евгеньевна Волкова Самара дәүләт медицина университетын тәмамлаган, 2012 елдан Нурлат ЦРБсының акушерлык – физиология бүлеге мөдире.**

- Иң мөһиме – хатын – кызларның бала табу этабына психик һәм физик яктан әзер булып килүе. Бала табу процессы җиңел узсын өчен булачак әниләр алдан ук әзерлек күрергә тиеш. Һәр йөклелек һәм һәр хатын - кыз уникаль. Шуңа да бала табу процессына кадәр махсус әдәбият, видеоязмалар белән танышу начар булмас. Бала табу ул – җәза урыны түгел, ә табигый процесс. Бала табу вакыты җиткән хатын-кызлар безнең бүлеккә перинотал консилиум рекомендациясе буенча диспансер картасы белән киләләр. Моннан тыш, хатын – кызлар паспорт, полис һәм СНИЛСның 2шәр данә күчермәләре, гигиена средстволары һәм киҗе – мамык материалдан халат, уңайлы күн икенче аяк киеме алып килергә тиеш. Бандаж, сөт суырткыч кебек нәрсәләрнең дә кирәк булуы мөмкин. Яңа туган бала өчен махсус киемнәр комплекты, пеленкалар, памперслар һ.б.лар кирәк булачак. Бала киемнәре дә табигый материалдан булу шарт.

Яшь әнинең төп багланышы - имезү. Шуңа да хатын - кыз йөклелек чорында ук туклану режимына зур игътибар бирергә тиеш: аксым, углевод, майлар, минераль тозлар, яшелчә, җиләк – җимеш, витаминнар тиешенчә булсын. Тәмәке тарту һәм алкогольдән баш тарту мәҗбүри. Күбрәк саф һавада булу шарт. Ә бала тудыру йортында яшь әниләргә яшелчәләрдән, җиләк - җимештән һәм татлы ризыктан баш тартырга туры килүе ихтимал. Чөнки бала туган минуттан ук ул аның сәламәтлеге турында кайгыртып яши башлый. Ә тудыру йортындагы ризык шуны күздә тотып әзерләнә.

Гомумән, бүлектә йөкле хатын - кызлар һәм яңа туган сабыйлар өчен барлык шартлар тудырылган. Агымдагы елда 20 хатын – кызга исәпләнгән бүлектә капиталь ремонт узды, яңа җиһазлар кайтарылды, медицина ярдәме бушлай күрсәтелә. Операция юлы белән бала табучылар 8 көн, ә табигый юл белән бала табучы әниләр 5 көннән соң чыгарыла. Бала туганнан соң әти-әнигә туу турында белешмә бирелә, әлеге белешмә нигезендә сабыйга туу турында ЗАГСтан таныклык алына. Яңа туган сабыйны бүлектән чыгарганда туу турындагы таныклык һәм полис дубликаты кирәк.

Бүлектә баланы тантаналы шартларда чыгару өчен махсус бүлмә эшли. Ул заманча бизәлгән, анда яшь әнинең шатлыгын уртаклашырга иң якыннары керә, бергәләшеп фотога, видеога төшә алалар. Гаиләдәге шатлыклы вакыйганы һәркем үзенчә бәйрәм итә. Соңгы вакытта аны мөмкин кадәр истә калырлык итеп үткәрергә тырышалар. Мондый хезмәт күрсәтүләр шактый хәзер. Тик шатлык яшь бала һәм әнигә катлауланулар китермәсен өчен инфекцияләрдән, салкын тидерүдән яки артык шау – шудан, физик нагрузкадан сакланырга киңәш итәбез. Йортта бала пәйда булу ата- ананың кайбер гамәлләрен чикләргә тиеш.

Баланы өйгә алып кайтуга да алдан ук әзерләнү кирәк: яңа туган баланың үз шәхси почмагы, шкафы, караваты, арбасы, киемнәре, уенчыклары булу шарт. Бүлмә җилләтелеп һәм дымландырылып торырга тиеш. Яшь әни һәм яңа туган баланы тудыру йортыннан каршы алганда машинада балалар автокәнәфие булырга тиешлеге хакында онытмагыз.

... Тугыз ай артта калды, хәзер сез әни булу шатлыгын кичерәсез. Шатлыклар белән бергә дәүләт ярдәмнәре турында да онытмагыз. Бала туганнан соң бер тапкыр бирелә торган түләүләр өчен белешмәләр җыеп баланың әтисе, я булмаса әнисе эшләүче оешмага тапшырырга кирәк. Моның өчен әти-әниләрнең паспорты, туу турында таныклык, ЗАГС белешмәсе, әни-әнинең эш урыныннан пособиене алмаганлыгы турында белешмә кирәк булачак.

Сез сәламәт бала үстерүдә иң җитди этапны үттегез – исән - сау сабыйны дөньяга китердегез. Аны физик һәм рухи яктан сәламәт итеп тәрбияләү турында проектыбызның киләсе чыгарылышларында сөйләшәчәкбез.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## САН

**Агымдагы елда районда барлыгы 442 сабый туган. Шуларның 213е– кыз бала, 229ы – малай. Бер пар игезәк дөньяга килгән. Иң зур баланың авырлыгы 4730 г, иң кечкенәсе – 1000 г. булган.**

**Видеосъемка. Т. 89276778886** Реклама

**Фотосъемка. Т. 8-9272437176** Реклама




**Все для выписки в «Мистер Паркер» и «Мистер Шар»:**
*Оформление шарами, плакаты, наклейки, специальные магниты на авто. Прокат аистов (мягких игрушек) на машину.*
*Сделайте ваш праздник ярче!*
**Мы ждем вас по адресу Кооперативная, 3 с 8.00 до до 19.00.** Реклама

**Большой ассортимент и низкие цены**
**- Товары для детей**
**- Косметические средства**
**- Товары для беременных и кормящих**
**- Средства женской гигиены.**
*Нурлат, ул.Гиматдинова, 52*
*Режимы работы: 8.00-21.00*
*Без перерывов и выходных.*
Реклама
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.

**АРТ-ДИЗАЙН**
**- Оформление машин на выписку,**
**- Распечатка фотографий,**
**- Именные бирки для новорожденных,**
**- Гравировка на кулонах и любые именные подарки.**
**Адрес: ул.Школьная, 26. Т.: 8-927-423-27-44, 2-04-44.**
*Выходной: суббота – воскресенье.*
Реклама

**Новое поступление в торговых точках на универсальном рынке у Сони:**
**- Ходунки, автокресла, санки, коляски, кроватки;**
**- Одежда с 0–15лет для мальчиков и девочек;**
**- Конверты на выписку, мягкие игрушки и многое другое.**
*Большой ассортимент, умеренные цены.*
Реклама

# Хокукый турнир үтте




**Узган атнада Фома мәктәбендә хокукый белемнәр һәм хокук бозуларны профилактикалау айлыгы кысаларында “Хокукый турнир” узды.**

6–7 сыйныф укучылары катнашкан турнирны җәмгыять белеме укытучысы Гөлфия Фәхриева оештырды.

Хокукый турнир танып-белү уены рәвешендә үтте, анда 7нче сыйныф укучылары, ике командага бүленеп, төрле биремнәрне үтәделәр һәм станцияләр буйлап хәрәкәт итеп, баллар туплыдылар.

Бурычларны үтәгәндә укучылар үзләренең хокуклары һәм бурычлары турында фикер йөрттеләр, башкаларның эшләрен бәяләргә, үз фикерләре белән уртаклашырга өйрәнделәр.

Командаларның белемнәренә директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары Гөлчәчәк Хуҗахмәтова бәя бирде.

- Балалар үз бурычлары һәм хокукларын яхшы беләләр. Безнең заманда бу бик мөһим, - диде ул.

Чарага мәктәптә “Минем хокукларым” дип аталган китаплар күргәзмәсе дә оештырылган иде. Анда куелган РФ Җинаять кодексы, РФ Конституциясе, РФ Хезмәт кодексы һәм башка китаплар буенча алар үз хокуклары белән җентекләп таныштылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар.

**Гүзәлия МӘХМҮТОВА**

ПРОКУРАТУРА ХӘБӘРЛӘРЕ

## ПРОКУРАТУРА СУД ПРИСТАВЛАРЫН ТИКШЕРДЕ

Тикшерү суд карарын үтәтүдә һәм башкарма гамәлләр кылганда суд приставлары тарафыннан “Башкарма производство турында”гы федераль закон таләпләрен тупас бозуга юл куелуын ачыклады. Мәсәлән, башкаручы-суд приставлары тарафыннан бурычлыларның яшәү яки вакытлыча тору урыннарына чыгу оештырылмый, теркәү органнарыннан бурычлының милке турында мәгълүмат соратылмый, бурычлыларны эзләтү буенча чаралар күрелми һ.б.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча, шәһәр прокуратурасы, ары таба ТРның Баш суд приставы адресына кертү өчен, ТР Прокуратурасына представление юллады.

## АТА-АНАЛАР КОМИТЕТЛАРЫ– ПРОКУРАТУРА ИГЪТИБАРЫНДА

**Нурлат шәһәр прокуратурасы мәгариф турындагы законның үтәлешен тикшерде. Балаларга белем бирү учреждениеләрендә ата-аналар комитетлары эшчәнлеген регламентлаучы локаль норматив хокукый актларны өйрәнү барышында законны бозу очраклары ачыкланды.**

Мәсәлән, нигезләмәдә ата-аналар комитетының функциясе белем бирү процессын оештыруда оптималь шартлар тәэмин итүдән (ата-аналар җәмәгатьчелеге көче белән матди-техник базаны ныгытуда, территорияне төзекләндерү һәм бинаны, балалар мәйданчыкларын ремонтлауда булышу; иганәчелек ярдәме күрсәтү) гыйбарәт дип билгеләнгән. Шул рәвешле, ата-аналар комитетларына мәгариф учреждениеләренә иганәчелек һәм башка ярдәм күрсәтү беркетелгән булып чыга, ә бу закон тарафыннан тыела.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча шәһәр прокуратурасы балаларга белем бирү учреждениеләрендә ата-аналар комитетлары эшчәнлеген регламентлаучы 25 локаль норматив хокукый актны кире какты.

Прокурор кисәтүләре каралды, нигезләмәләргә тиешле үзгәрешләр кертелде

**Нурлат шәһәре прокуратурасы материаллары буенча**

РАЙОН ТОРМЫШЫННАН КҮПТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘРНЕ **NURLAT-TAT.RU** САЙТЫНДА УКЫЙ АЛАСЫЗ

# Әнием, кадерлем минем...

29 НОЯБРЬ – ӘНИЛӘР КӨНЕ

**Бу якшәмбедә Әниләр көне уңаеннан һәр кеше өчен иң олы, иң кадерле булган мәрхәмәтле һәм изге күңелле кешеләр балалары һәм якыннарыннан котлаулар кабул итә. Без дә котлауларга кушылабыз һәм редакциябездә эшләп лаеклы ялга чыккан ветераннарыбызны, хәбәрчеләребезне һәм барлык укучыларыбызны әлеге ихлас һәм гүзәл бәйрәм белән котлыйбыз. Көннәрегез һәрчак шатлыклар белән тулып торсын, ихтирам һәм хөрмәт тоеп кадерле булып яшәгез.**



**Бикколда** яшәүче кадерле әниебез **Гамбәр Гаяз кызы Әхмәтшинаны** Әниләр көне белән ихлас тәбрик итәбез. 5 балага гомер биреп, бүген дә алар һәм оныклары дип янып яшәүче киң күңелле, олы йөрәкле әниебезгә ныклы исәнлек, имин тормыш телибез.

Син - иң газиз кеше безгә,<br>
Син - яшәү чыганагы.<br>
Синнән дә сабыр әниләр<br>
Бар микән җирдә тагы?<br>
Өебезнең кояшы син,<br>
Һәркемгә җитә җылың.<br>
Әти белән парлы килеш<br>
Җырлагыз тормыш җырын.<br>
Ул тормышның һәр мизгеле<br>
Сөенеч белән тулсын,<br>
Гомереңнең һәрбер көне<br>
Шатлыктан гына торсын.<br>
Бәйрәмнәрең котлы булсын,<br>
Безгә бергә бик рәхәт,<br>
Кылган изгелекләреңә<br>
Әни, сиңа мең рәхмәт.

**Барлык балаларың, килен-кияүләрең, оныкларың һәм оныкчыкларың.**



**Киекле авылында** гомер итүче кадерле әниебез **Минҗиһан Хәмәтгата кызы Садыйкованы** Әниләр бәйрәме белән ихлас котлыйбыз.

Әни! Син бөтен гомереңбуена "балаларым" дип яшәдең. Әтиебез белән 49 ел гомер кичереп, безнең барыбызга да югары белем алырга, олы тормыш юлына чыгарга булыштыгыз. Безгә генә түгел, бөтен авылга үрнәк гаилә булдыгыз. Барысы өчен дә рәхмәт сезгә.

Кадерле әниебез! Без сиңа озын гомер, нык исәнлек, күңел тынычлыгы, бәхетле тормыш, матур картлык телибез. Алдагы көннәреңдә дә балаларың, оныкларың, оныкчыкларыңның кадер – хөрмәтендә исән – сау яшәргә насыйб булсын үзеңә.

Кайчан барсак – киң күңелле,<br>
Каршылыйсың ачык йөз белән.<br>
Авырлыклар җиңеләеп китә<br>
Синең әйткән җылы сүз белән.

**Барлык балаларың, кияүләрең, килennәрең, оныкларың, оныкчыкларың исеменнән Кизләүдә яшәүче кызың Флюра һәм киявең Илгизәр гаиләсе.**



**Якты Кул** авылында яшәүче кадерле әниебез, әбиебез **Затия Якуп кызы Низаметдинованы** көзнең якты бәйрәме – Әниләр көне белән чын күңелебездән котлыйбыз. Әниебез, син – яхшы күңелле, сабыр, кешелекле, олы җанлы, ягымлы кешебез – без сине ихлас күңелебездән ихтирам итәбез һәм яратабыз. Безне ачык йөз белән каршы аласың, үз кулларыгыз белән булдырган җылы һәм якты туган нигезебездә тәмле ризыклар белән сыйлыйсың, бар яктан да ярдәм итәсез, рәхмәт сезгә. Алдагы тормышың кайгы-хәсрәтсез үтсен, сәламәт бул, матур гомер ит, балаларыңның-оныкларыңның игелеген күреп, һәрвакыт шулай изге, сабыр, шат, күңелле булып озак яшә.

Рәхмәт, әнкәй, тудырганың өчен,<br>
Аяз көннәр булсын җаныңда.<br>
"Бисмилләһ" дип син шатланып уян<br>
Гомереңнең һәрбер таңында.<br>
Ныклы иман һәрчак юлдаш булсын,<br>
Шатлык тоеп типсен йөрәгең.<br>
Авырлыклар сине урап үтсен,<br>
Кабул булсын һәрбер теләгең.

**Сине яратып, хөрмәт итеп балаларың, оныкларың.**



Әни җирдә иң газиз, якын кеше. Әниләрне хөкүмәт тарафыннан да зурлыйлар, хөрмәтлиләр. Безнең Фома авылында яшәүче әниебез **Амалия Габбас кызы Сафиуллина** да - Ана медале белән бүләкләнүче. Ул - 7 бала тудырып, аларга күкрәк сөтен имезеп, ана назы биреп тәрбияләп үстерүче. Ана назын тоеп яшәү – бәхет бит ул. Сиңа ничә генә яшь булмасын – биш яшьме, әллә иллеме, һәрвакыт әни, аның назлы карашы, кайгыртуы кирәк. Әниеңне яратуың никадәр зур булса, яшәвең шулкадәр якты, шатлыклы була. Әйе, әни – һәркемгә якын, изге, газиз кеше. Әниләрнең ягымлы, йомшак сүзләре балага гомер буена юлдаш була. Әниебез һәрвакыт безнең янда – авырганда да, борчылганда да, шатланганда да. Аның күзләре шундый мөлаем һәм ягымлы. Әйтерсең, бөтен дөньяның акылын һәм сабырлыгын җыйган диңгез! Ә әнкәйнең куллары иң-иң җылы, иң-иң кадерле куллардыр, мөгаен. Шул ягымлы куллар сиңа кагылуга, бөтен кайгыларың югала. Ә „балам" дип арканнан сыйпаса, гүя очар канатлар үсә. Ә сүзләре... сүзләре шундый татлы, туң йөрәкләрне эретерлек җылы.Нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә, җитмәс төсле. Әниебез, сиңа саулык-сәламәтлек, кайгысыз-хәсрәтсез тыныч тормыш, озын гомер телибез.

**Ихлас теләкләр белән: барлык балаларың, килен-кияүләрең, оныкларың һәм оныкчыкларың.**

## АНА ЙӨРӘГЕ

Әни. Бу исемнән дә кадерлерәк һәм изгерәк нәрсә бар икән? Әниләр көненә багышлап 34нче балалар бакчасында үткән бәйрәмдә нәниләр үз әниләренә булган бар җылылыкларын, ярату һәм назларын ирештерергә тырыштылар. Алар әниләргә бүләкләр әзерләделәр, шигырьләр укыдылар, җырлар башкардылар.Аннан алар үз әниләренең ярату һәм игелек тулы йөрәкләре рәсемен ясадылар. Бу көнне әниләр өчен дә төрле конкурслар оештырылды.

Бәйрәм әниләргә балаларның һәм җәмгыятьнең рәхмәтен ирештерү юлында матур чара булып узды.

**Ландыш Шәвәлиева,Заречный поселогы**



**Нурлатта** яшәүче кадерле әниебез, зур әниебез **Рәмзизә Усман кызы Юнысованы** Әниләр көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Әниебез, безнең өчен синнән дә кадерлерәк, синнән дә якынрак кеше юк бүгенге көндә. Син – безнең сердәшчебез дә, киңәшчебез дә, авыр чакта ярдәм кулы сузып, җылы сүзләр белән юатучыбыз да. Укытучы дигән игелекле һөнәр иясе булып, гомереңбуена балалар күңеленә белем орлыклары салдың, безне дә тормышны яратырга, намуслы һәм тырыш булырга өйрәттең. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа.

Сөйкемле карашың кояшка тиң -<br>
Бар тормышны нурга күмәсең.<br>
Бу дөньяның барлык хикмәтләрен<br>
Бары тик син генә беләсең.<br>
Тормышта гел ярдәм итеп тора<br>
Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең;<br>
Иркәлисең, яратасың, юатасың,<br>
Кичерәсең, аңлыйсың да үзең.<br>
Сәламәтлек, озын гомер язсын,<br>
Гел көләч һәм яшь бул хәзергечә!<br>
Күңелең синең күтәренке булсын,<br>
Сөенеп-сөендереп мең-мең яшә!

**Изге теләкләр белән балаларың һәм оныкларың.**

## 600 ГАИЛӘ ТҮЛӘҮЛӘР АЛДЫ

Пенсия фондының Нурлат районы идарәсе 600 гаиләгә ана капиталы средстволарыннан бер тапкыр бирелә торган түләүләрне башкарды инде. Ана капиталы средстволарыннан бер тапкыр бирелә торган түләү 20000 сум тәшкил итә. Гаиләләр әлеге сумманы көндәлек ихтыяҗларга тота алалар. Мондый түләүләрне алу өчен ПФРга гаризаны 2016 елның 31 мартынан да соңга калмыйча тапшырырга кирәк.





**Биккол** авылында яшәүче иң кадерле, иң якын, иң яраткан кешеләребез – **Мәнҗия Мәхмүт кызы Закирова һәм Ислامия Миннехан кызы Әһлиуллинаны** дөньядагы иң гүзәл бәйрәм – Әниләр көне белән котлыйбыз. Җәннәт әниләрнең аяк астында, диләр. Әниләрнең изге күңелле булуы, балалары өчен җаннарын да бүлеп бирергә әзер торуыннан чыгып әйтелгән сүзләр бу. Безнең әниләребез дә шундый: аларның күңеле бары изгелек, мәрхәмәт һәм шәфкатьтән генә тора һәм анда барыбызга да урын җитә. Әниләребез, сезгә нурлы, якты көннәр, сәламәтлек тулы озын гомер, бәхет телибез.

Нигә генә тиңлик икән сезне?<br>
Сез бит әни –<br>
Тормышыбызның тиңсез бизәге!<br>
Йөрәк түрләрегездән<br>
өзелеп төшкән<br>
Бәгыребезнең бездер – үзәге.<br>
Кояш дисәк, кояштан да кайнар,<br>
Аебыз дисәк, айдан яктырак!<br>
Бу дөньяның тиңсез байлыгы сез,<br>
Юктыр беркем сездән якынрак!<br>
Җирдә кояш нуры балкыгандай,<br>
Сез балкыйсыз безнең күңелдә.<br>
Тормышыбыз синең белән матур,<br>
Рәхмәтлебез сезгә гомергә...

**Ихлас теләкләр белән: балаларыгыз Ленар-Фаилә, оныкларыгыз Диана һәм Динара. Безнең теләкләргә башка балаларыгыз һәм оныкларыгыз да кушыла.**

# ВӘЗГЫЯТЬ

ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

## “Мин бүген бик бәхетле”


Лилия Мөбарәкшина фотосы

**Маргарита Литта берничә ел элек язган бу юллар аның бүгенге күңел халәтен башкаларыннан күбрәк ачып бирәдер сыман.**

Тыйнак, мөлаем, аңардан җылылык һәм яктылык бөркелеп тора. Ә омтылышы, тормышны ярату, үҗәтлек никадәр аңарда?! Мөстәкыйль “Пластилиновый дождь” җыентыгы чыкканчы мартта “Ел хатын-кызы-2015” конкурсының “Хатын-кыз – рухилык” номинациясендә, апрельдә “Страницы семейной славы” Халыкара Интернет-конкурсында җиңүче булды, сентябрьне исә күптән көтелгән шигырьләр җыентыгы чыгуы белән билгеләп үтте, ә октябрьдә тыйнак кына гомер бәйрәме – 35 яшьлеген үткәрде. Ә бу елның вакыйгалар эстафетасы “Дуслык” газетасында эшли башлавына 10 ел тулу белән түгәрәкләнер, мөгаен. Маргарита тормышының бу мизгелләренә карап, бер нәрсәнең дә очраклы булмавын аңлыйсың. Мәсәлән, Җиңүнең 70 еллыгына багышланган Халыкара конкурста җиңми мөмкин дә түгел: ни дисәң дә, Советлар Союзы Герое Григорий Кузнецов оныгы бит. Ә китапның исеме бала чагыннан килә. Ноябрьнең бу көннәрендә җыентыкны бастыруның инициаторы булган җирлекара китапханәдә Маргаританың беренче китабын тәкъдир итү узды.

- “Пластилиновый дождь” шигырен мин үземнең абыема багышладым. Бала чакта мин яшеннән бик курка идем, һәм шул вакытта без аның белән өйдә утырып, пластилиннан яңгыр әвәли торган идек, - дип уртаклашты яшьлек, мәхәббәт, Туган ил, әниләр турындагы шигырьләр җыентыгы авторы. Ританың тормышында әнисе – төп кеше. Ул рухландыручы да, хөкемдар да. Әмма Нина Григорьевна әйтүенә караганда, ул кызының шигырь белән мавыгуын башта җитди кабул итмәгән.

– Бу гомерлеккәдер дип уйлап та карамадым, - ди Нина Кузнецова. – Мин бүген кызым белән бик горурланам һәм аның сәләтен күреп алган, каядыр киңәш биргән, ярдәм иткән укытучысына рәхмәтле. Мин хәзергә кадәр Ританың дәфтәрләрен саклыйм.

Маргарита исә үзе дә тәкъдир итү кичәсендә беренче һәм башка остазларын да игътибарсыз калдырмады, аларның ярдәме белән аның шигырьләре башта үзенең туган Шентала районы газетасында, соңрак “Первая капель”, “Созвездие Нурлат”, “Асамат кепере”, “Новая литературная волна” һәм башка җыентыкларда дөнья күрәләр.

Китапны тәкъдир итү кичәсендә Маргаритага күңелләре белән дә, каләмнәре белән дә иң якын кешеләре килгән иде. Хәтта Самара өлкәсеннән туганнары да бар иде. Җылы халәттә Маргаританың шигырьләре дә үзенчәлекле яңгырады. Аларны тыңлаганда, шигырьләрдә синең дә хисләрең чагылыш табадыр сыман, алар күңелнең иң тирән кичерешләрен кузгата, аларда никадәр яшәү сулышы, битараф калу мөмкин дә түгел. Ә җирле шагыйрә Антонина Халипа Маргаританың беренче китабына багышлап шигырь дә язган.

Без, Ританы шагыйрә генә түгел, кул эшләре остасы һәм чуваш бүлеге каршындагы “Салават күпере” түгәрәге җитәкчесе, Татарстандагы чуваш язучылары Берлеге әгъзасы, ике ул үстерүче әни, яраткан хатын, кыз һәм килен итеп тә белүче коллегалары, аның күңеленең очышта һәм яңа офыкларны яуларга әзер икәнлегенә ышанабыз. Бу очышы озакка булсын, безне иҗади җимешләре белән сөендерсен һәм уртак горурлыгыбызга сәбәпче булсын иде.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**

### МУЗЕЙДА ТОЛЕРАНТЛЫК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

16 ноябрьдән 23 ноябрьгә чаклы үткәрелгән толерантлык атналыгы кысасында Гадулла Кариев музеена кунаклар чакырдык. 19 ноябрьдә безгә мәчеттә гарәп теле өйрәнүче Колбай Мораса урта мәктәбе укучылары һәм аларның мөгаллимәсе Фәния Шакирова килде. Өченче-тугызынчы сыйныфларда белем алучы егет-кызлар шимбә, якшәмбе көннәрендә бик теләп өстәмә дәресләргә йөриләр. Мәктәп янәшәсендәге 100 еллык мәчетнең эченә бер керсәң, чыгасы да килми, диләр алар. Шулкадәр дустанә атмосфера, яңадан-яңа мәгълүмат алабыз, дип сөенәләр.

Кунаклар, гадәттәгечә, яңа күргәзмә белән таныштылар. Фонд хезмәткәре Наилә Гайнетдинова һәркайсы турында тәфсилләп сөйләде. Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллинның тормыш юлына багышланган китап, өченче мәхәллә мәчете сурәте, дини басмалар һәм башка төрле тематик экспонатларны балалар кызыксынып карады. Фәния апаларының күчтәнәчләре белән Г.Кариев музее самавырыннан чәй эчтеләр. Шуннан соң җәен ТНВ каналы иҗат төркеме төшереп киткән ярты сәгатьлек телефильмны күрсәттек.

Очрашуны йомгаклап, Фәния Шакирова һәм Люзия Вәлиуллина катнашучыларга төрле дин, төрле милләт вәкилләренең җәмгыятьтә тигез хөрмәткә, игътибар һәм ихтирамга лаек икәнен ассызыкладылар.

Люзия **ВӘЛИУЛЛИНА**, Г.Кариев музее директоры

## Ашау эшләгәнгә карап булачак

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

**Киләсе елдан Татарстанның агросәнәгать тармагына бирелә торган бюджет акчаларын гадәттәгечә һәр хуҗалыкка тигез итеп түгел, ә аларның эш нәтиҗәләренә карап бүләргә җыеналар.**

Моның өчен исә октябрь ае азагында төрле күрсәткечләрне исәпкә алып, республика районнары һәм хуҗалыкларының рейтингы төзелде. Субсидиянең коэффициенты шуннан чыгып билгеләнәчәк тә. Дөрес, рейтинг әлегә 2014 ел нәтиҗәләре буенча төзелгән (2015 ел нәтиҗәләре буенча рейтинг соңрак булачак) һәм кемнең күпме ярдәм аласын төгәл генә әйтеп булмый. Әмма ул кайбер авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләрен уйланырга мәҗбүр иткәндер.

### ИГЕНЧЕЛЕК БУЕНЧА – БЕРЕНЧЕ КАТЕГОРИЯДӘ

Игенчелек буенча Нурлат республика районнары арасында 10нчы урында һәм 79 балл белән беренче категориягә кергән. Категорияләр саны исә өчәү. Биредә беренче урында 134 балл белән Балтач районы булса, иң соңгы урын нибары 16 балл җыйган чирмешәнлеләрдә. Рейтингны билгеләгәндә күбрәк нәрсәгә игътибар бирелгән соң?

– Рейтингны төзегәндә 6 индикатор: уртача уңыш, югары репродукцияле орлыклар куллану, бөртекле-кузаклы һәм майлы культураларның масса өлеше, күпьеллык үләннәр мәйданнары һәм файдаланылмаган сөрү җирләренең масса өлеше исәпкә алынды, - дип аңлата районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. – Шулай да зуррак рольне уртача уңыш уйнагандыр дип уйлыйм. 2014нче елда республикада бер гектарга уртача уңыш 21 центнер тәшкил итсә, район буенча ул 25,1 центнер булган. Әлбәттә инде, башка күрсәткечләрнең дә яхшы булуы кирәк. Хәер, яхшы уңышның нигезендә шулар ята да бит инде.

Игенчелек буенча исә районнар белән бергә инвесторларның эшчәнлегенә дә рейтинг ясалган. Биредә дә өч категория бар, Нурлатның “АгроИнвест” ИК җәмгыяте – өченче урында һәм беренче категориягә кергән. Ә менә безнең районда да бүлекчәсе булган “Кызыл Шәрыкъ-Агро” – икенче категориядәге инвесторлар арасында.

### ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘ ӨЧЕНЧЕДӘН УЗМАГАН

Терлекчелек тармагы буенча рейтингны төзегәндә 100 гектар авыл хуҗалыгы җирләренә туры килә торган җитештерелгән сөт һәм ит күләме, бер берәмлек мөгезле эре терлектән алынган ит, савым сыерларның нәтиҗәлелеге һәм 100 сыердан алынган бозаулар саны исәпкә алынган. Әгәр дә район 200дән дә артыграк балл җыйган икән, ул беренче категориягә керә. 149-195 балл җыйган районнар исә икенче категорияле булып санала. Баллар күләме 140тан да кимрәк икән, бу – өченче категория дигән сүз. Кызганычка каршы, Нурлат районы бу рейтингта 117 балл белән 31нче урында гына. Бу, әлбәттә, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләрен дә борчый һәм алга таба эшне оештыруда өстенлекләрне билгеләргә мәҗбүр итә.

– Рейтингта алдынгы позициягә чыгу өчен иң беренче чиратта продуктлылыкның югары, ит һәм сөт җитештерү күрсәткечләренең зур булуы кирәк, - ди бу уңайдан Ислам Салихович. – Әлбәттә, район хуҗалыкларында дуңгызчылык тармагы бетерелүнең дә йогынтысы юк түгел. Җитештерүчәнлекне арттыру максатыннан хуҗалыкларда симертү төркемнәре булдыруны бурыч итеп куябыз. Ә сөтчелекне күтәрү шул ук барлык технологик таләпләрне истә тотып эшләүгә кайтып кала. Моңа һәр хуҗалыкта җитди игътибар бирү генә кирәк.

Аерым инвесткомпанияләргә килгәндә, “Агро-Инвест” биредә икенче категориядә, ә менә баллары 100дән кимрәк булган “АгроРазвитие” белән “Нурлат сөте” өченче категориягә кергән. Шунысын да әйтергә кирәк: бу рейтингта беренче урынны биләп торучы “Продпрограмма” АПК ОООсы 561 баллга ия.

### ҺӘР ХУҖАЛЫКНЫҢ ҮЗ УРЫНЫ

Гомумән, игенчелек буенча рейтингта районнар һәм инвесткомпанияләр белән беррәттән һәр хуҗалыкның үз урыны бар. Хуҗалыклар исә чәчүлек мәйданнарыннан чыгып өч төркемгә бүленгән: 1000 гектардан артыграк җире булганнар, 500дән 1000 гектарга кадәр һәм 500 гектардан кимрәкләр. Җирләре 1000 гектардан артыграклар арасында Нурлат хуҗалыкларында иң зур балл (118) - “Южная” АФ җәмгыятендә, икенче позиция – “Сөләйманов Ә.И” КФХсында (116), “Нурлат сөте” хуҗалыгы да 104 балл белән беренче категориядә. Икенче категориядә исә Нурлат районының 4 хуҗалыгы – “Агромир СЙ”, “ИРС”, “Алиев А.Б” КФХсы һәм “ВЗП-Билярск”. Өченче категориядә – “Тулпар Агро” һәм “Космос” ОООлары. Чәчүлек мәйданнары 500 гектардан кимрәк хуҗалыклардан 1нче категориягә керүчеләр арасында нурлатлылар күренмәсә дә, икенче һәм өченчеләрдә бар үзе. Өченче категориядә 2014 елны минуслы күрсәткечләр белән тәмамлаучылар да юк түгел.

– Рейтинг безгә үз эшчәнлегебезгә анализ ясар, чагыштырыр өчен тулы күзаллау бирә һәм алга таба күрсәткечләрне яхшыртуга мөмкинлекләрне, резервларны барларга, эшкә җигәргә мәҗбүр итә. Хәзер менә 2015 ел рейтингын көтәбез, - ди бу уңайдан хуҗалыгы урта рейтингларда булган фермерларның берсе.

Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсендә исә 2015 ел рейтингы алдагысыннан начар булмаска тиеш, дип фаразлыйлар. Терлекчелектә күрсәткечләрнең быел яхшырак булуын истә тотып, өскәрәк менү мөмкинлеге булуына да өметләнәләр. Хуҗалыклар да үз күрсәткечләреннән чыгып фаразлар ясый башлаганнардыр. Әмма фараздан бигрәк эшләү тәртибен үзгәртү турында уйлану кирәктер. Ни дисәң дә, алга таба ашау эшләгәнгә бәйле булачак бит.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

# КОТЛАУ. ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Яңа Әмзә** авылында туып үсеп, хәзерге вакытта Нурлат шәһәрендә гомер итүче **Шамил Әсхәт улы Тимбиковка** 26 ноябрьдә 60 яшь тулды.

Кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабабыз! Сине ихлас йөрәктән юбилейлы туган көнең белән тәбриклибез һәм хәерле озын гомер, корычтай нык сәламәтлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы, якыннарыңның игелеген күреп, хөрмәтен тоеп озак еллар яшәвеңне телибез.

Туган көнең – юбилееӊ белән
Чын күңелдән сине котлыйбыз.
Сәламәтлек, шатлык – куанычлар,
Иман байлыгы сиңа телибез.
Бәхет сиңа, саулык сиңа,
Кайгы – хәсрәтләр күрмә,
60 яшеңне тутырдың,
Тутыр әле 100не дә.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, кияүләрең һәм оныкларың.**

"ДУСЛЫК" ПОЧТАСЫННАН

## КӨЗ ҖИҢҮЛӘРГӘ БАЙ

Көз–гүзәллеге һәм табигать могҗизалары белән күңелләрне дулкынландырырлык ел фасылы. Безнең "Тирмәкәй" балалар бакчасы каеннар арасына урнашканлыктан, бу чорда әкияти манзара уртасында калгандай була. Һәр елны бездә көз темасына төрле конкурслар һәм күргәзмәләр үтә. Быел да мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар әти-әниләре белән берлектә "Үз кулларың белән– могҗиза" күргәзмәсендә катнаштылар һәм иң уңышлыларын Бөтенроссия конкурсларына юлладылар. Нәтиҗәдә "Декоратив- кул эшләре иҗаты" номинациясендә берничә призлы урынга да лаек булдылар. Данияр Ибраһимов, Диана Митракова эшләре беренче, Самира Абдуллина, Алиса Медведева, Даша Гусарова, Сабина Сәйфетдинова һәм Ксюша Макарова ясаган әйберләр икенче, ә Амелия Сингатуллина хезмәте өченче урынны алды. Алина Кадыйрова һәм Рамазан Илялов "Көз буяулары" конкурсының дипломантлары булдылар.

**Т.РОМАНОВА, Г.АБДУЛЛИНА,**

**БАКЧА ТӘРБИЯЧЕЛӘРЕ**

**Информация для предпринимателей Нурлатского муниципального района**

30 ноября 2015 года в 11:00 часов в малом зале городского Дворца культуры состоится образовательный семинар для предпринимателей «Бизнес-десант». Проводит семинар Министерство экономики Республики Татарстан. Участникам семинара предлагаются бесплатные готовые бизнес-идеи, упакованные в готовые комплекты документов, с помощью которых можно в короткий срок запустить новое направление бизнеса.

Перед участниками семинара выступят опытные бизнес - тренеры, которые расскажут о секретах маркетинга в кризисное время, нюансах тендерного законодательства и налогообложения.

**Димитровградский завод профлиста «МИР КРОВЛИ» реализует**

ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы.
Утеплитель.
Парогидроизоляция.
Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 8(84235) 2-75-25.**
**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**

Реклама

КЫСКАЧА

## ШӘҺӘРДӘ АВТОБУС ТУКТАЛЫШЛАРЫ АРТА

Кормыш, Интернационалчылар, Мәктәп, Совхоз. Шәһәрдә яңа куелачак тукталышларның исемнәре үк аларның кай тирәдә буласын күрсәтеп тора. Кормыш тукталышы – шәһәрнең БПО каршында, интернационалчылар –Әфганчылар бистәсендә, мәктәп – Югары Нурлат мәктәбе янында, совхоз – Ключи поселогы каршында.

– Әлеге тукталышлар халык белән очрашулар барышында кергән мөрәҗәгатьләр буенча куела, – диде шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. –Хәзер барлык 4 тукталышны төзү буенча да эш бара.

**Сәкинә НУРУЛЛИНА**

## МӘКТӘП ҮЗИДАРӘЛӘРЕ ЯРЫШТЫ

**Шәһәрнең 2нче, Киекле һәм Биляр Озеро урта мәктәпләре районда укучылар үзидарәләрен үстерү буенча иң яхшы учреждениеләр булдылар.**

Укучылар үзидарәләрен үстерүче гомуммәгариф оешмалары Бөтенроссия конкурсының республика этабына сайлап алу турында районның 20 мәгариф учреждениесе катнашты. Сайлап алу туры сишәмбе көнне шәһәрнең 9нчы урта мәктәбендә узды.

- Сайлап алу турында барлык командалар да мәктәп үзидарәләрен үстерүдә системалы һәм нәтиҗәле эшләүләрен күрсәттеләр, - ди Балалар иҗаты үзәге директоры урынбасары Миләүшә Мөхәмматова. – Призлы урыннар яулаган өч мәктәп район данын республика этабында яклаячак.

## СПОРТ ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ

Узган атнада Г.Хөсәенов исемендәге бала – үсмерләр спорт мәктәбендә традицион с көрәше фестивале узды. Анда Нурлат, Аксу һәм Базарлы Матак, Самара өлкәсеннән 80 б катнашты. Бу көнне 8–15 яшьлек малайлар кызлар спортның 5 төре - кикбоксинг, бокс, мия кул сугышы, каратэ, кекусинкай буенча сынашты һәм матур нәтиҗәләр күрсәтте Җиңүчеләргә медальләр һәм Мактау грамота ры тапшырылды.

## БӨТЕНРОССИЯ ФОРУМЫНДА КАТНАША

Казанда 26-27 ноябрьдә "Святость матер ства" Бөтенроссия программасының дүрте форумы уза. Анда 400дән артык кунак кат ша. Чара кысаларында бүген гаилә сәясәт багышланган түгәрәк өстәлләр эшендә ра башкарма комитетының ЗАГС бүлеге җитәкч Гөлшат Евлахина да катнаша.

**Зилия ӘКСАНО**

г. Самара, Балхашский проезд 34, оф. 109
тел: + 7 (846) 98-907-98; 225-21-55; 97-27-048
моб/тел: +7 (937) 98-11-333
сайт: amiteko-samara.ru
mail: amiteko@yandex.ru

Амитеко
выбор очевиден




• Качество, подтвержденное результатами испытаний в международных аккредитованных центрах (Германия, Швейцария, Чехия).

• Широкий ассортимент цветов, фактур и форм: возможность подбора под любой архитектурный стиль дома — от классики до hi-tech.*

*Хайтек

• Высокий коэффициент энергоэффективности в любое время года: экономия на работе кондиционеров летом и отопительных приборов зимой.

• Автоматика ведущих европейских производителей: гарантия безопасности и удобства управления.


Стоимость наиболее распространенных размеров гаражных ворот

| Размеры ворот Ширина/Высота, мм. | Розничная стоимость, руб. Ворота «Дорхан» 42 мм пр-во Россия | Розничная стоимость, руб. Ворота «Алютех» 40 мм пр-во Беларусь | Розничная стоимость, руб. Ворота «Hormann» 42/20 мм пр-во Германия |
|---|---|---|---|
| 2500х2125 | 27 900 | 29 600 | 35 900 |
| 2500х2250 | 28 700 | 30 000 | 35 900 |
| 2500х2500 | 30 300 | 32 200 | 39 900 |
| 2750х2125 | 30 500 | 32 500 | 40 990 |
| 2750х2250 | 32 000 | 33 000 | 41 990 |
| 2750х2500 | 34 900 | 36 700 | 45 990 |
| 3000х2125 | 35 400 | 37 800 | 44 990 |
| 3000х2250 | 35 800 | 36 200 | 45 990 |
| 3000х2500 | 36 900 | 38 500 | 49 990 |
| Стоимость монтажных работ, включая комплект привода - 3500 руб. | Комплект привода SE-500KIT, (Sectional-500) пр-во Дорхан (Россия) | Комплект привода ASG600/3KIT-L, пр-во AN motors (Китай) | Комплект привода Ecolift, пр-во Hormann (Германия) |
| | 7 700 | 8 000 | 12 000 |


*Цены актуальны только для Нурлатского р-на !*

Кодовое слово "НУРЛАТ"


**Автоматические шлагбаумы**




**Распашные автоматические ворота**



**Откатные автоматические ворота**



**Секционные автоматические ворот**



# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

*НУРЛАТ шәһәре өчен декабрь аена намаз вакытлары (2015 ел)*

| Көн саны | Көн исеме | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.12.2015 | Сиш | 06:03 | 07:33 | 12:00 | 13:29 | 15:17 | 17:07 |
| 02.12.2015 | Чәрш | 06:05 | 07:35 | 12:00 | 13:28 | 15:16 | 17:06 |
| 03.12.2015 | Пәнҗ | 06:06 | 07:36 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:06 |
| 04.12.2015 | Җом | 06:08 | 07:38 | 12:00 | 13:27 | 15:15 | 17:05 |
| 05.12.2015 | Шим | 06:09 | 07:39 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:05 |
| 06.12.2015 | Якш | 06:10 | 07:40 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:05 |
| 07.12.2015 | Дүш | 06:12 | 07:42 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:05 |
| 08.12.2015 | Сиш | 06:13 | 07:43 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:04 |
| 09.12.2015 | Чәрш | 06:14 | 07:44 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:04 |
| 10.12.2015 | Пәнҗ | 06:16 | 07:46 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:04 |
| 11.12.2015 | Җом | 06:17 | 07:47 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:04 |
| 12.12.2015 | Шим | 06:18 | 07:48 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:04 |
| 13.12.2015 | Якш | 06:19 | 07:49 | 12:00 | 13:25 | 15:11 | 17:04 |
| 14.12.2015 | Дүш | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 13:25 | 15:11 | 17:04 |
| 15.12.2015 | Сиш | 06:21 | 07:51 | 12:00 | 13:25 | 15:11 | 17:04 |
| 16.12.2015 | Чәрш | 06:22 | 07:52 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:05 |
| 17.12.2015 | Пәнҗ | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:05 |
| 18.12.2015 | Җом | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:05 |
| 19.12.2015 | Шим | 06:24 | 07:54 | 12:00 | 13:26 | 15:12 | 17:06 |
| 20.12.2015 | Якш | 06:25 | 07:55 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:06 |
| 21.12.2015 | Дүш | 06:25 | 07:55 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:06 |
| 22.12.2015 | Сиш | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 13:27 | 15:13 | 17:07 |
| 23.12.2015 | Чәрш | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:07 |
| 24.12.2015 | Пәнҗ | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:08 |
| 25.12.2015 | Җом | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 13:29 | 15:15 | 17:09 |
| 26.12.2015 | Шим | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 13:29 | 15:16 | 17:09 |
| 27.12.2015 | Якш | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:30 | 15:17 | 17:10 |
| 28.12.2015 | Дүш | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:31 | 15:18 | 17:11 |
| 29.12.2015 | Сиш | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:32 | 15:19 | 17:12 |
| 30.12.2015 | Чәрш | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:12 |
| 31.12.2015 | Пәнҗ | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:34 | 15:21 | 17:13 |

Приглашаем на постоянную работу в нефтедобывающую компанию

**ГК ОЙЛЭКТ (ООО «ТНГК-Развитие»):**

- *Электрогазосварщика*
- *Инженера – строителя*
- *Специалиста со знанием программ Visual или AutoCAD (создание схем нефтепроводов)*

**Место работы: г. Нурлат, ул. Советская 140.**
**Телефон отдела кадров. (843)200 99 98, Лидия Сергеевна.**
**Резюме направлять на эл.почту: mardanovals@oilect.ru**

Реклама




- ✓Оформление по ТК РФ
- ✓Иномарки, постоянное обновление
- ✓Высокий уровень зп
- ✓Корпоративная связь
- ✓Страховка
- ✓Ремонт в СЦ
- ✓При приеме обязательно наличие у водителя карты для тахографа ЕСТР

**ЗВОНИТЕ: +7-962-567-36-23**
**ТЕЛ. В НАБЕРЕЖНЫХ ЧЕЛНАХ: +7(8552)77-82-82**

*Делко. Реклама

**2 декабря с 14 до 15 ч. в Ц.Р.Аптеке №94 ул.Гагарина,10**

## Слуховые аппараты

Аналоговые от 5900 р. Цифровые, сверхмощные 11000-17000 р. **Усилители звука** 1500-4500 р. **Батарейки** – 30 руб.

***Только сегодня скидки до 2000 руб!*** *

выезд по району - тел- **89225036315**

*скидка предоставляется 02.12.2015 г.

Подробности у консультантов.

Организатор ИП Коробейникова Е.М.

Св № - 305183220300021

**ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА**

Реклама

**Натяжные потолки.**
**Любой сложности. Одно-, двухуровневые.**
**Т. 8-927-413-37-58. Иван.**

12+ “ТНТ-Нурлат” тәкъдим итә

**30 НОЯБРЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**2 ДЕКАБРЬ**
“Нурлат хәбәрләре”,
“Татнефть” хәбәрләре.

**4 ДЕКАБРЬ**
**“Нурлат хәбәрләре”.**
**“Сиңа дигән җырым”**, музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **1, 3, 5 декабрьдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

## РЕМОНТ ОБУВИ

*29 ноября с 10.00 до 16.00 в здании типографии (ул. К.Маркса, 19, 2 этаж)*

**Кировская обувная фабрика производит ремонт старой осенней и зимней обуви до полного её восстановления и обновления:**

* *Замена подошвы с перетяжкой, включая весь внутренний ремонт (смена изношенного меха, подносков, запятников).*
* *Полная замена нижней части сапог (натуральная кожа, замша, лак).*
* *Изменение фасона, высоты каблука, толщины подошвы.*
* *Подгоняем по полноте и размеру ноги.*
* *Подошва не ломается и не скользит (термоэластопласт).*

Реклама **ПОДАРИТЕ ВАШЕЙ ОБУВИ НОВУЮ ЖИЗНЬ!!!!**

**29 ноября в здании типографии (ул. К.Маркса, 19) Ульяновская обувная фабрика проводит выставку-продажу обуви из натуральной кожи (пр-во Ульяновск, Беларусь, Казань).**

**Новое поступление нижнего белья «МИЛАВИЦА» и домашней одежды «Клевер», магазин «Метелица», 2 этаж, отдел нижнего белья. Т. 8-927-402-11-65.**

**Теплицы разных размеров**
-Стандартные, -Усиленные
-Оцинкованный, окрашенный каркас
-Заводское качество
-Сборка, доставка по звонку
Кредит (предоставляют АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк»).
г.Нурлат, универсальный рынок, магазин «Сад огород»
**Тел.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06.**

## ООО «ВСЕ ДЛЯ КРОВЛИ»

**Профнастил. Сайдинг. Металлочерепица.**
**Доборные элементы. В наличии и под заказ.**
**Г. Нурлат, ул. Куйбышева, 36, офис 10** *(около ж/д вокзала).*
**Т.: 8(84345) 2-01-26, 8-929-726-57-97.**

Реклама

## Рәхмәт белдерәбез

Кадерле тормыш иптәшем, яраткан әниебез **Саҗидә Вәлимәрдән кызы ХӘЙРУЛЛИННАНЫ** соңгы юлга озатуда матди һәм рухи ярдәм күрсәткән туганнарга, дусларга, Иске Әлмәт авылы җирлеге башлыгы Равил Хисамовка, күршеләргә, аеруча Гыйззәтовлар, Гафиятуллиннар гаиләләренә, Җәвидә Сөнгатуллинага, авылдашларга олы рәхмәтебезне белдерәбез. Ходай сезне кайгылардан сакласын.

**Тормыш иптәше Җәүдәт, балалары.**

### НЕДВИЖИМОСТЬ

*1-комнатная квартира, г. Казань (21 век, Советский район). Т. 8-927-032-22-75.
*дом. Т. 8-927-462-17-01.
*новый дом без отделки, ул. Рябиновая. Т. 8-927-406-17-05.
*2-комнатная квартира. Т. 8-927-247-22-44.
*гараж, Гиматдинова, 91. Т. 8-927-403-50-37.
*3-комнатная квартира, 4 этаж, ул. Кариева. Т. 8-937-616-99-16.
*комната, ул. Нефтяников, 2, 18 кв. м. Т. 8-927-673-46-87.
*4-комнатная квартира, продрынок. Т. 8-927-249-00-86.
*кафе. Т. 8-937-287-90-01.
*дом, ж/д. Т. 8-937-594-02-94.
*элитный коттедж, ул. Дачная, 1-28. Т. 8-927-047-41-24.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2112», 2008 г/в. Т. 8-927-417-02-72.
*«ВАЗ-21124», 2006 г/в, гур, европанель. Т. 8-937-617-05-03.
*«ВАЗ-2107», 2009 г/в. Т. 8-927-429-00-87.
*«ИЖ-2126-ода», 2003 г/в, цвет синий океан, цена при осмотре. Т. 8-927-418-04-79.
*«Тайота-Авенсис», 2009 г/в, пробег 81000, цвет оливковый, коробка механическая, торг уместен. Т. 8-937-776-59-18.

### ДРУГОЕ

*бычки, телята разного возраста. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*услуги погрузчика. Т. 8-927-672-31-49.
*ПГС, песок, бут камень, жом. Т. 8-927-672-31-49.
*телята, доставка. Т. 8-927-414-07-18.
*телята, сено, солома. Доставка бесплатно. Т.: 8-929-301-67-76, 8-937-309-03-57.
*поросята. Т. 8-937-770-46-59, 8-84344-4-98-72.
*доски осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.
*бычки-молодняк. Т. 8-927-870-49-62.
*картофель, Т. 8-927-241-58-83.
*памперсы 2 размер. Т. 8-919-683-52-05.
*корова, телята. Т. 8-937-610-57-99.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*тушки гусей, индюшат (300 руб/кг), доставка. Т. 8-927-448-04-76.
*ПГС, жом, песок, дрова колотые. Т. 8-937-629-98-97.
*жом. Т. 8-903-061-05-65.
*перегной, чернозем, камни для фундамента. Т. 8-927-463-63-17.
*живые гуси, тушки, потроха свежие и копченные,. Т.: 8-965-605-18-77, 8-937-588-27-15.
*козел породистый, 9 мес. Недорого. Т.: 2-29-30, 8-927-455-21-08.
*норковая шуба б/у, б/у прихожая, б/у тумба, САК, гаражные ворота без коробки. Т. 8-927-466-10-32.
*пшеница, ячмень. Доставка бесплатная. Т. 8-937-776-33-35.
*жом, песок, ПГС, цемент, керамзит. Т. 8-927-401-51-91.
*мед липовый только у нас, доставка. Т. 8-937-297-30-70.
*котел напольный «Очаг», бак и насос на отопление, трубы «сэндвич» на дымоход. Т. 8-927-678-41-09.
*свинина, говядина кусками. Т. 8-937-183-52-60.
*гуси. Доставка. Т.: 8-937-285-92-20, 4-14-00.
*бык. Т. 8-937-580-65-06.

**Теплица «НАДЕЖНАЯ» от завода 3х6 – 16 000, гарантия 3 года.**
**Т.: 8-927-040-97-37, 8-917-923-95-82, 8-929-722-29-89.**

*бык 1 год 6 мес. с. Андреевка. Т6 3-92-40, 8-937-581-66-38.

### РАЗНОЕ

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*химчистка мягкой мебели и автомобилей, доступные цены. Т. 8-987-007-17-44.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-927-481-51-72.
*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.
***ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.**
*ремонт пластиковых окон. Т. 8-927-249-54-24.
***РЕМОНТ, НАСТРОЙКА: КОМПЬЮТЕРОВ, НОУТБУКОВ, Wi-Fi, ИНТЕРНЕТА. ВЫЕЗД. Т. 8-937-005-14-51.**
*отделочные работы. Т. 8-937-620-00-60.
*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.
*замена электропроводки. Т. 8-929-728-93-36.
*ремонт обуви. Т.: 8-937-620-79-20, 8-917-247-90-54. Сергей.
*доставка жома. Т. 8-987-294-31-04.
*выполняем любые отделочные работы. Т. 8-919-634-89-45.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.
*выравнивание стен, потолков, обои, плитка, шпаклевка. Т. 8-927-455-25-35.

### ТРЕБУЮТСЯ

*повара, бармены. Т. 2-39-99.
*Вахта в г. Москву. Сборщики(-цы), грузчики, комплектовщики(-цы), упаковщики(-цы), фасовщики(-цы), кассиры. Т. 8-927-272-91-84.
*крановщик со стажем. Т. 8-937-283-70-69.
*ООО «Спецэнергомонтаж» электрогазосварщик. Обращаться пер. Заводской, 1А (ЖБИ). Т. 2-50-90.

### СДАЮТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*квартира, посуточно. Т.: 8-927-456-05-69, 8-986-712-11-79.
*рабочие места под парикмахерскую, маникюр, педикюр, ул. Кариева. Т. 8-937-283-73-19.
*в аренду в парикмахерской рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.
*в аренду торговые площади, офисные помещения. Т. 8-917-274-93-96.
*4-комнатная квартира под офис. Т. 8-927-242-59-26.

### СНИМУ

*1-2 комнатную квартиру, с/з и ж/д не предлагать. Т. 8-917-397-00-48.
*1-комнтаную квартиру, теплую. Т. 8-927-434-39-40.
*1-комнатную квартиру в центре. Порядок гарантирую. Т. 8-927-406-67-81.

### КУПЛЮ

*«ВАЗ», иномарки. Дорого. Т. 8-929-723-31-23.
*АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.
*пух гусиный, мокрый, сухой, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*закупаем шкуры КРС по высоким ценам. Т. 8-927-045-44-86.
*кирпичный дом в черте города. Т. 8-927-695-33-66. *КРС. Т. 8-927-481-30-38.
*КРС, шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-412-29-99.
*шкуры КРС. Т. 8-937-281-75-63.
*мед липовый 2014 г. и 2015 г. и пчелопродукцию оптом. Приезжаем сами, деньги и тара сразу. Т. 8-927-328-70-37.
*баллоны кислородные. Т. 8-987-292-01-10.
*участок, Северо-Восточный мкр. Т. 8-927-466-10-32.

### ПОТЕРИ

*утерянное удостоверение оператора котельной №10983 от 19.03.2003 г., выданный УКК НГДУ «Нурлатнефть» на имя Ривгата Сирачовича Нуретдинова, считать не действительным.

## Кайгы уртаклашабыз

Шәһәрнең 4нче урта мәктәбе администрациясе һәм коллективы, әнисе **Миннеруй Габетдин кызы ӘХМӘТҖАНОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, мәктәп директоры Солтан Фәйзерахман улы Әхмәтҗановның, аның гаиләсенең, туганнары һәм якыннарының авыр кайгыларын уртаклашалар. Ходай сезгә бу авыр югалтуны күтәрерлек сабырлык һәм түземлек бирсен.

